# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында”
Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 29 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында” 2008 елның 22 маендагы 22-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 5 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш); 2012, № 1) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:
а) 2 өлештә:
8 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;
11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“11) федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урман саклауны) гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеген һәм урманнарда федераль дәүләт янгын күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү;”;
б) 3 өлешнең 9 пунктында “7 – 9” саннарын “7 һәм 9” сүзләренә алмаштырырга;

2) 7 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:
“10 елга бер мәртәбә 20 куб.м. га кадәр – авыл хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен түләүсез вакытлы файдалануга бирелгән урман кишәрлекләрендә вакытлыча корылмалар төзү һәм (яисә) ремонтлау өчен.”;

3) 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3 бүлек. **Урман үсентеләрен сату-алу шартнамәләре нигезендә агач әзерләүнең һәм агач булмаган урман ресурсларын әзерләүнең аерым очраклары**

8 статья. **Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә дәүләт ихтыяҗларын яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен агач әзерләүнең аерым очраклары**

Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә дәүләт ихтыяҗларын яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен агач әзерләүнең аерым очракларына урманны карау максатында кисүләр, санитар-савыктыру һәм янгынга каршы чаралар үткәргәндә, әгәр әлеге чаралар урманнарны саклауга, яклауга һәм торгызуга дәүләт заказын яисә муниципаль заказны бер үк вакытта урман утыртмаларын сату белән урнаштырганда исәпкә алынмаган булса, агач әзерләү керә.

$8^{1}$ статья. **Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә яңа ел бәйрәмнәре өчен гражданнар, юридик затлар тарафыннан чыршылар һәм (яисә) башка ылыслы агачлар әзерләүнең аерым очраклары**

Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә яңа ел бәйрәмнәре өчен гражданнар, юридик затлар тарафыннан чыршылар һәм (яисә) башка ылыслы агачларны урман кишәрлекләре бирелмичә әзерләүнең аерым очракларына күрсәтелгән агач булмаган урман ресурсларын ел саен 1 ноябрьдән 31 декабрьне дә кертеп булган чорда әзерләү очраклары керә.”;

4) 9 статьяга “агач булмаган урман ресурслары әзерләргә һәм җыярга,” сүзләреннән соң “яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) башка ылыслы агачлардан тыш,” сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2012 елның 22 декабре
№ 88-ТРЗ